**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәренең муниципаль гомуми белем бирү учреждениесе Таҗи Гыйззәт исемендәге 3 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе**

# Тема: “ Исем” темасын кабатлау

**4нче сыйныф (рус төркеме)**

**Сингапур укыту методын кулланып уздырылыган ачык дәрес эшкәртмәсе**

**Укытучы: Муллахмәтова Ф.М.**

**21 февраль 2014 ел**

**ТЕМА:** Исем темасын кабатлау**.**
**МАКСАТ:**
1) Исемне кабатлау. Төрле формадагы исемнәрне сөйләдә һәм язуда дөрес куллану
2) Логик фикерләү, креатив уйлау сәләтен үстерү. Күнегүләр ярдәмендә белемнәрне камилләштерү,дөрес җөмләләр төзү күнекмәләрен булдыру.
3) Татар теленә карата ихтирам ,коллективизм сыйфатын тәрбияләү.

**ҖИҺАЗЛАУ:**
**Тезник чаралар:** ноутбук
**Таратма материал:** битләр, каләмнәр,карточкалар.

**ДӘРЕС ТИБЫ :** белемнәрне гомумиләштерү һәм системалаштыру, ягъни кабатлау-йомгаклау дәрес.

**МЕТОД ҺӘМ АЛЫМНАР:** Практикум дәрес, биремнәр үтәү.

**КУЛЛАНЫЛГАН СТРУКТУРАЛАР :**
- **МЭНЭДЖ МЭН,**
- **КОННЕРС**
- **ТИК- ТЭК- ТОУ,**
- **КОНТИНИУС РАУНД РОБИН**

**Дәрес барышы:**

**1. <u>Оештыру өлеше:</u>**

*1)* Укучыларның дәрескә әзерлекләрен тикшерү. ХАЙ ФАЙВ структурасы ярдәмендә.

2) Дәрескә кирәкле әсбабларны барлау.

**2. Фонетик зарядка**

Сатучы, келәм, җиһаз, малай, апа, йөзек, тәлинкә, өстәл, оекбаш, чаңгы
- Сүзләрне уку, Кем? Нәрсә? соравын кую
- Кем? Нәрсә? соравына нинди сүз төркеме җавап бирә?
- Димәк, бүген дәрестә Исем темасын кабатлыйбыз.
- Кагыйдәсен искә төшерик.
- Исем предметны белдерә, Кем? Нәрсә? соравына җавап бирә. Сан, килеш, тартым белән төрләнә.

**3. Кабатлау.**
**Коннерс структурасы.**

Мин сезгә карточкалар таратам, аңа сүзләр язылган. Сез бу сүзне игътибар белән укыйсыз, һәм кирәкле почмакны сайлыйсыз.

- Сүзне укыйсыз, почмакның исемен язып куясыз (30 сек). Басагыз, сайлаган почмакка барыгыз.
- Парлап басасыз, һәм фикер алышасыз. Рәхмәт әйтергә онытмагыз. Ни өчен бу почмакны сайладыгыз? (1 мин.).
- Фикерләрегезне тыңлыйбыз. (Һәр почмактан берәр укучыны тыңлау)

- Алдагы эшне без **ТИК - ТЭК – ТОУ(крестики нолики)** структурасы ярдәмендә үтиячәкбез.
- Моның өчен сезнең өсләлләрегездә карточкалар куелган .
- Икенче номерлы партнер әлеге битләрне өстәлнең уртасына ,тәртип буенча 3*3 рәвешендә урнаштыра.
- Сез хәзер сүзләрдән 3 җөмлә төзергә тиеш буласыз.Ләкин теләсә ничек түгел, яки горизонталь ,яки вертикаль,яки диагональ буенча.
- Башка сүзләр өстәргә ярый.
- Сезгә моның өчен 4 минут вакыт бирелә. Вакыт башланды.(Таймер куела).
- Вакытыгыз бетте.Хәзер сез **КОНТИНИУС РАУНД РОБИН (продолжительный раунд робин) структурасы** ярдәменә командада бер-берегезгә чират буенча җөмләләрегезне укыйсыз,истә калдырырга тырышасыз яки язасыз.
- Беренче булып дүртенче номерлы партнер үзенең беренче җөмләсен укый һәм шулай чылбыр буенча эшне дәвам итәбез. Аннары икенче җөмләне укыйсыз һәм өченче җөмләне.
- Моның өчен сезгә 3 минут вакыт бирелә.вакыт китте (Таймер куела)
- Молодцы. Минем ........ өстәлдәге ....... номерлы укучының җөмләсен ишетәсем килә. Җөмләләр дөрес төзелмәсә төзәтәсез (Берничә укучының җөмләләре укыла.)
- **4. <u>Йомгаклау:</u>**

**Билгеләр кую**. Үзбәя бирү.

**Сорауларга җавап бирү**:

- Укучылар искә төшерик нинди сүз төркемен кабатладык бүгенге дәрестә?
- Кем миңа килешләрне санап чыгала?

Дәрес бетте ,чыгарга мөмкин.Саубулыгыз.